# Мәктәп хәбәрчесе

**№7** (№20) ноябрь 2020 ел

*Түбән Майна урта мәктәбе газете*

**Тел. 8 (84344) 4-38-46** **sch1644maina@mail.ru**


***/Мөхәррир сүзе /***

## *Олимпиадада катнашу укучыга файдалымы?*




Хәзерге чорда мәгариф өлкәсендә предмет олимпиадалары хәрәкәте бик киң җәеллгән. Олимпиадаларның төп максаты – укучыларда танып-белү эшчәнлегенә кызыксыну уяту, сәләтле һәм талантлы балаларны ачыклау, алар белән эшләү тәҗрибәсе туплау. Бу юнәлештән, әлбәттә, безнең мәктәп укытучылары да читтә калмый.

Укучыларның мөмкинлекләрен барлап, сәләтен ачыклап, аларны төрле фән олимпиадаларына җәлеп итәргә тырышабыз. Чөнки олимпиада – ул тренировка, күбрәк, яхшырак, тирәнрәк, сыйфатлырак белү омтылышы. Бу җиңүгә омтылыш кына түгел, ә характерның да чыныгуы. Биредә баланың күңеленә якынрак, кызыклырак фәне ачыклана. Моның өчен, әлбәттә, балаларга мәктәп программасыннан тыш белемнәр белән дә кызыксынырга туры килә. Мондый хезмәт аларның күзаллауларын шактый киңәйтә һәм нәтиҗәдә фән буенча төп база белемнәрен алырга мөмкинлек бирә. Бу – беренчедән. Икенчедән, укучы өчен аралашу, башкалар белән ярыша алу да аның үз-үзенә ышанычын арттыра. Башлангыч сыйныфлардан башлап йөргән саен, нечкәлекләрен күбрәк белә бара укучы. Шуның белән ул кайда да югалып калмаячак. Стандарт булмаган, иҗади фикерләүгә, нәтиҗәләр ясый белүгә, булган мәгълүматны мөстәкыйль рәвештә анализлый белүгә исәпләнә олимпиада биремнәре. Үз җавабыңны дәлилли белү дә күздә тотыла.

Олимпиадаларда катнашу гына түгел, җиңү дә мөһим. Җиңүләр, бирәк тә алга таба, күбрәк мөмкинлекләр ача. Югары уку йортларына кергәндә өстәмә баллар, өстенлекләр бирәчәк, конкурс дәрәҗәсенә карап, стипендия яки уку өчен грант алу мөмкинлеге дә бирелә.

Тик барыбер күп кенә укучылар олимпиадаларда катнашудан баш тарта, чөнки шәхси вакытларын әзерләнүгә сарыф итүнең мәгънәсен күрми. Әгәр дә укучы җиңелүдән курка икән, «уңышсызлыкка» дучар булса да, ул киләсе олимпиадага әзерләнгәндә нәрсә барлыгын аңлый, таләпләрдән чыгып, икенче төрле әзерләнәчәк.

Һәр олимпиада чарасы – белем биеклегенә чираттагы баскыч, уңышка, үсешкә ачкыч. Шуңа күрә, укучым, үзеңнең мөмкинлекләреңне барла, тырыш, син булдырасың. Алдагы олимпиадаларда уңышлар телибез!

***Мөхәррир Фәнүзә Гафиятуллина,***
***татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

## *Бәйрәмегез белән, газиз әниләр!*

***Кояш чыкса - көн якты,***
***Әни кайтса - өй якты.***
***Чөнки газизмнең йөзе***
***Якты йолдыздан якты.***

***Алар бала күңеленә***
***Тамчылап сала сафлык.***
***Китерсәк иде аналарга***
***Гомер буена шатлык.***



Быелгы уку елында санитар таләпләр буенча күп кеше катнашындагы күңел ачу чаралары уздыру рөхсәт ителми. Шуңа да карамастан, **ӘНИЛӘР бәйрәме** уңаеннан мәктәптә үзенчәлекле чара уткәрелде. Укучылар иң кадерле булган әниләренә багышлап видеокотлау ясадылар. Әлеге котлаулар hhttps//vk.com/video93376557 _456239020 ссылкасы белән урнаштырылды. Теләгән кеше аларны шушы каналларга кереп карый ала. Һәр сыйныфның котлавы үзенчәлекле һәм тирән эчтәлекле килеп чыкты.

**ӘНИЛӘРЕБЕЗ!** Барыгызга да ныклы сәламәтлек, имин тормышлар телибез. Яратып, саклап, кадерләп үстергән газиз балаларыгыз бары шатлык кына китерсен. Алар өчен биргән җылыгыз, йокысыз төннәрегез, борчу-мәшәкатьләрегез балалар тарафыннан изгелеккә, игелеккә әйләнеп кайтсын.

Һәрбер гаиләгә тигезлек, сәламәтлек теләп

*“**Мәктәп хәбәрчесе” редколлегиясе**.*



## Кошлар безнең ярдәмгә мохтаҗ

Кошлар – безнең дусларыбыз, ярдәмчеләребез. Алар үсемлекләрне һәм агачларны төрле корткычлардан саклыйлар. Кошларны, чын мәгънәсендә, табигать санитарлары дип атасак та ялгышмабыз. Салкын һәм карлы кыш айларында кошларга ризык табу нык кыенлаша. Шул сәбәпле, кошалар безнең ярдәмгә бик мохтаҗ. Ноябрьның беренче кары төшүгә үк, мәктәп директоры Рафик абый укучыларга җимлекләр ясау буенча конкурс игълан итте. Конкурста катнашкан укучылар һәрберсе үз осталыгыннан, мөмкинлегеннән чыгып, җимлекләр ясады. Без аларны мәктәп ишегалдындагы агачларга урнаштырдык. Җимлекләргә кошлар яратып ашый торган азыклар салынды. Аннан соң кайсы җимлеккә кошлар беренче килер икән дип күзәтеп тордык. Җимлекләр кошларга салкын, озын кышларны җиңел кичерергә булышыр дип өметләнәбез.

Җимлекләр бик күп төрле була. Аларны кәгазь тартмалардан да, тактадан да, буш шешәләрдән дә ясап була. Иң мөһиме – эшкә теләк белән килү.

***Зөлфирә Сафиуллина, IX сыйныф укучысы.***

## *"Иң куркынычсыз каникуллар"*

Каникул көннәрендә районда "Иң куркынычсыз каникуллар" дип аталган видеороликлар конкурсы оештырылды. Бу бәйгедә катнашу өчен авылның мәдәният йорты җитәкчесе Нәҗметдинова Ләйсән апа, мәктәп укучылары белән берлектә, бик кызыклы видеоролик төшерде. Конкурс нәтиҗәләре буенча, безнең мәдәният йорты район буенча беренче урынга лаек булды. Район мәдәният бүлеге Ләйсән апаны һәм видеога төшкән укучыларны бик зур уенчык аю һәм диплом белән бүләкләде.

Ләйсән апа, әле эшли генә башлауга карамастан, төрле мәдәни проектларны бик оста итеп башкару сәләтенә ия. Җәй айларнында аның авыл тормышына багышланган видеофильмы, шулай ук, районда беренчелекне алган иде. Без аңа киләчәктә дә, иҗади эшләрендә зур уңышларга ирешүен теләп калабыз.



***Самат Гафиятуллин,  VII сыйныф  укучысы.***

### */Укучылар иҗаты /*

Гәзитебезнең бу санынннан алып, Түбән Майна һәм Иске Татар Әдәмсуы мәктәпләрен төрле елларда тәмамлаган укучылар иҗат иткән шигырь-хикәяләрне һәм истәлек язмаларын бастыра башлыйбыз. Мәктәп еллары барыбыз өчен дә сагынып искә алына торган дәвер. Үз истәлекләрен “Мәктәп хәбәрчесендә” бастырырга теләгән укучылардан хатлар көтеп калабыз.

## *Туган як*

Туган якның гүзәл табигате,
Үзенә тарта кая барсаң да.
Газиз туган ягым, синнән башка
Яши алмам олы булсам да.

Яшь чагымда газиз туган якның
Нигә белмибездер кадерен.
Яшьлегемне менә үйлыймын да,
Бигрәкләр дә өзелә бәгырем.



Әй, дусларым, шуны әйтәм сезгә
Онымагыз туган якларны.
Еракларга киткәч, сагынасың
Туган якта булган чакларны.

Түбән Майна мәктәбенең 1999-нчы елгы чыгарылыш укучысы
**Туктамышева Лилия Тәбрис кызы**

### */Котлыйбыз! /*




Ноябрь аенда I сыйныф укучысы **Нурматова Асия**, VI сыйныфтан **Хәйруллин Айназ,** VII сыйныфтан **Гафиятуллин Самат,** X сыйныфтан **Насыйрова Сара** туган көннәрен билгеләп үтәләр.

Кадерле дуслар! Сезне туган көннәрегез белән тәбрик итәбез! Сезгә тән һәм рух сәламәтлеге, тәртипле, тырыш, уңган шәхесләр булып үсүегезне телибез!

## *Акчаларда – ил тарихы* *==/ТАССРның 100 еллыгына/==*

Билгеле булганча, тарих язуда төп һәм иң ышанычлы чыганак булып язма материаллар санала. Ләкин аерым төбәкләр тормышын чагылдырган урта гасырларда язылган документларны табу мөмкин эш түгел. Бары тик кайбер урыннарда сакланып калган язулы кабер ташлары һәм борынгы акчалар гына шул җирлектә кайчан кешеләр яшәгәнлеге турында төгәл мәгълүмат бирә алалар.

Безнең мәктәп музеенда сакланылучы акчалар тупланмасы туган җиребезнең борынгы тарихы турында сөйләүче бик мөһим чыганак булып торалар. Музейдагы акчалар тупланмасында барлыгы йөзгә якын тәңкә тупланган. Аларны сугылу вакыты буенча шартлы рәвештә ике төркемгә аерып карарга була. Беренче төркемгә татар-мөселман акчалары, икенчесенә Мәскәү патшалыгы һәм Рәсәй империясе чорындагы тәңкәләр керә.

Татар-мөселман акчалары түбәндәгечә классификацияләнде:




- 970-980 нче елларда сугылган “самани” тәңкәләр;
- “Акчасыз дәвер” дип йөртелгән XI-XII гасырларда акча урынына йөргән кургаш коелмалар һәм көмеш кисәкләре;
- Багдад хәлифәсе Насыйр лиддин-илләһ исеменнән Бату хан тарафыннан 1240-нчы елларда сугылган бакыр акчалар;
- Бату һәм Бәркә ханнар тарафыннан Мәнгү каһан исеменнән 1251-1259-нчы елларда сугылган бакыр акчалар;
- 1260-1312-нче еллар арасында сугылган Ариг Буга, Мәнгү Тимер, Түлә Буга, Туктай ханнарның акчалары;
- 1312-1360-нчы елларда сугылган Үзбәк, Җанибәк һәм Булат ханнарның акчалары;
- 1390-1420-нче “болгавыр” елларда сугылган тәңкәләр һәм1420-1435 нче елларга караган Олуг Мөхәммәт хан акчалары.

Мәскәү патшалыгы һәм Рәсәй империясе чоры акчалары түбәндәгечә төркемләнде:

- “мордовкалар” дип йөртелә торган акча урынына XVI гасыр – XVII гасырның беренче яртысында йөргән тәңкәләр;
- 1613-1676-нче елларга караган патшалар Михаил Федорович һәм Алексей Михайлович акчалары;
- Франция короле Людовик XIV исеменнән 1637-1678-нче еллар арасында сугылган санау жетоннары;
- Петр I нең 1701-1721 нче еллар арасында сугылган акчалары;
- 1726-1759 нчы еллар арасында сугылган Екатерина I, Анна Ивановна, Елизавета Петровна акчалары;
- 1783, 1798 нче елларда сугылган Екатерина II һәм Павел I акчалары.

Әлеге нумизматик материаллардан чыгып караганда, авылыбыз җирләренең тарихи үткәне түбәндәгечә тасвирлана. Соң дигәндә 970-нче еллардан алып Кала урынында һәм Тукморза болыны буендагы кырда халык төпләнеп яши башлый. Бу урыннардан табылган археологик материалларның үзара тәңгәллеге дә ул җирләрдә халыкның бер үк вакытта яшәгәнлеген дәлилли. Шуңа күрә бу ике урынны бердәм торак комплекс буларак карарга кирәк. Шулай исәпләгәндә бу җирдә болгарларның бер кечерәк шәһәрчеге булганлыгы ачыклана. Чирмешән өстендәге текә ярлы тау битендә урнашкан, чама белән 1,5 гектар мәйданлы калада ныгытылган кирмән, ә елганың аргы ягындагы 6-7 гектар тирәсе җирне биләгән тигезлектә шәһәрчекнең бистәсе урнашкан булган. Монгол яуларыннан соң да бу урыннарда тормыш гөрләп барган. Бары тик XIII-XIV гасырлар чигендә, ни сәбәпледер, кала һәм “Тукморза” буендагы бистәдә тормыш туктала.

Аннан соң, XIV гасырның беренче яртысында Майна инеше Чирмешәнгә кушылган урында бер авыл барлыкка килә. Ул җирдән чыккан табылдыклар бу авылда халык тимер эретү белән шөгыльләнгәнлеген һәм көнкүрештә чуеннан эшләнгән савыт-сабаны күп кулланганлыгы турында сөйли. Ә кала белән Тукморза буеннан тимер шлагы табылса да, чуен калдыклары гомумән юк диярлек. *(дәвамы 4-нче биттә)*




***Акча табылдыклары буенча җирлектәге авыллар арасында дәвамчылык***

## Шахмат, шашка – зирәкләр уены

Көзге каникул көннәре безнең мәктәпнең шахмат-шашка уйнаучы укучылары өчен вакыйгаларга бик бай, күңелле, мавыктыргыч үтте. Яшь булуына карамастан, шактый тәҗрибәле уенчыбыз – **Гафиятуллин Фаил**, Чаллы шәһәре үткәргән ТАССРның 100 еллыгына багышланган тиз шахмат **(рапид)** төре буенча турнирда 2010-2011 елгы малайлар арасында 1-нче урынны яулады. Уен барлык шахматчылар арасында үтсә дә, бүләкләү кызлар, малайлар, яшь аермалары буенча категорияләргә бүленеп бирелде.

6-нчы ноябрь көнне Аксубай районы яшьләр һәм спорт комитеты "Авыл таңнары" газетасына язылу мөмкинлеген бирүче XXV шахмат турнирын үткәрде. Ул онлайн форматта үтте. Бу ярышта да, мәктәп һәм авыл данын яклаучы **Гафиятуллин Фаил** булды. Уен нәтиҗәләре буенча, ул 1-нче урынны яулап, 2021 елның беренче яртыеллыгына **"Авыл таңнары"** газетасына бушлай язылу хокукына ия булды.

Каникулның соңгы көннәре килеп җиткәне тоелмый да калды. 7-нче ноябрь көнне мәктәптә укучылар арасында шашка-шахмат турниры уздырылды. Әлеге чараның әйдәүчесе һәм оештыручысы – авылыбызның ветераннар советы рәисе **Гафиятуллин Госман** абый булды. Алдан ярышта катнашырга теләүчеләр күп булмаса да, соңрак уенчылар саны 12-гә җитте. Монда бакча балалары да, төрле яшьтәге мәктәп укучылары да катнашты. **Шахмат турнирында** егетләр арасында, 1-нче урын **Гафиятуллин Фаилгә**, 2-нче урын **Хәйруллин Айназга**, 3-нче урын **Хәйруллин Данилга** бирелде. Кызлар арасында 1-нче урынга **Нурматова Зәйнәп**, 2-нче урынга **Хәбибрахманова Хәнифә**, 3-нче урынга **Нурматова Асия** лаек булды. **Шашка турниры** нәтиҗәләре буенча егетләр арасында 1-нче урынга **Гафиятуллин Фаил**, 2-нче урынга **Хәйруллин Данил**, 3-нче урынга **Залиев Салават** иреште. Кызлардан 1-нче урынга **Нурматова Зәйнәп**, 2-нче урынга **Хәбибрахманова Хәнифә**, 3-нче урынга **Насыйрова Кәүсәр** ия булды. Әлеге чарада бакча балаларының шахмат белән кызыксынуын күрү - иң күңелле яңалык иде. Барлык укучылар да Госман бабалары әзерләгән тиешле призларын алдылар, бер катнашучы да бүләксез калмады. Госман бабайга һәм аңа турнирны оештырырга ярдәм иткән Хәйруллина Рузилә белән Нәҗметдинова Ләйсән апаларга гәзитнең редколлегиясе исеменнән зур рәхмәтебезне белдерәбез.



***Виктория Нукина, IX сыйныф укучысы.***

*(дәвамы, башы 3-нче биттә)* Шулай булгач, Майна буендагы авылның алардан соң барлыкка килгәнлеге ачыклана. Бу авыл бер гектар тирәсе генә мәйданны биләп, чагыштырмача кыска вакыт яшәүгә карамастан, безгә "Майна" атамасын биреп калдырган булырга тиеш. Шул ук елларда хәзерге авылның көнбатыш читендәге "Зур чирәм" дигән болын урынында Алтын Урда чорына караган бер авыл яшәгән.

1360-нчы еллардан хәзер "Иске авыл җире" дип аталучы чама белән 10-12 гектар мәйданны биләгән җирдә халык урнашып яши башлый. Бу авыл кешеләре дә, Майна буендагылар кебек үк, тимер эретү белән шөгыльләнгәннәр һәм бик күп күләмдә чуен савыт-саба кулланганнар. Алда әйтеп үтелгәнчә, татар акчалары бу авылның яшәешен 1435-нче еллар, ә тәңкәләрнең шомару дәрәҗәсеннән чыгып исәпләгәндә, 1450-1460-нчы еллар белән чикли. Шул елларда башланып киткән Казан ханлыгының үз акчасы булмаганлыктан, ул дәвернең тарихы буенча нумизматика ярдәм итә алмый. Шулай да, ул чорда авылның булганлыгына ишарәле торган документ бар. 1743-нче елда чукындыручылар, Иске авылның мәчетен җимергәч, аның әле урыслар Казанны алганчы ук төзелгәнлеге турында белешмә язып калдырганнар.

Рәсәй патшаларының акчалары халыкның кала урынында һәм "Иске авыл" җирендә 1613-1645 нче еллардан алып, 1759 нчы елларга чаклы яшәгәнлеген дәлилли.Тарихи документларда иске авыл "Майна", "Чирмешән", "Салкын Чишмә" исемнәре белән атала. XVIII гасыр башында Иске авылга Самара ягыннан ачлыктан качып килгән чуашлар килеп урнаша. 1748-1749 нчы еллар тирәсендә чуашлар һәм берничә татар кешесе каратуннар тарафыннан көчләп чукындырыла. Ул чор законнары буенча, чу-кынмаган халыкка чукын-дырылганнар янында яшәргә ярамаган. Шуннан соң безнең бабайлар авыл-ның хәзерге урынына күченеп урнашалар. Акча табылдыклары да "Иске авылның" бушап калган вакытын төгәллек белән раслый.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, татар-мөселман акчалары авылыбыз җирләрендә Болгар дәүләте оешкан X гасырдан алып Казан ханлыгы барлыкка килгән XV гасыр уртасына кадәр өзлексез рәвештә халык яшәгәнлегенә ныклы дәлил булып тора. Рәсәй патшаларының акчалары "Иске авылның" XVII гасыр башыннан XVIII гасыр уртасына чаклы узган гомерен күрсәтә. Шулай итеп борынгы акчалар авыллар тарихын торгызуда алыштыргысыз чыганак булып тора.

***Рафик Насыйров, тарих укытучысы, тарих фәннәре кандидаты***

Газетаны гамәлгә куючы – Түбән Майна урта мәктәбе
Мөхәррир – Фәнүзә Гафиятуллина
Редколлегия әгъзалары:
Әминә Туктамышева, Сара Насыйрова
Виктория Нукина, Рузилә Мөхәммәтова
Зөлфирә Сафиуллина